**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2024 елның 15 феврале

Халык алдында тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы - Совет рәисе инициативасы белән үткәрелде, 2023елның 25 декабрендәге 150-РС номерлы карар белән билгеләнде.

Кече Елга авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2023елның 25 декабрендәге 150-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2023елның 29 декабрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2023елның 27 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;
3. 2023елның 29 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Кече Елга авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларда катнашучылар - җирлек территориясендә даими яшәүче гражданнар, әлеге территория чикләрендә урнашкан һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шулай ук әлеге капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 10 гыйнварындагы 12/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Ачык тыңлаулар башлану турында 2024 елның 10 гыйнварындагы 12/исх хәбәр басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2024 елның 11 гыйнварында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегенең рәсми сайтында;

2. 2024 елның 19 гыйнварында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);

3. 2024 елның 25 гыйнварында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе рәисе урынбасары- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Кондратьева Алена Александровна - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе секретаре.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты материаллары экспозициясе 2024 елның 29 гыйнварыннан 2024елның 2 февраленә кадәр үткәрелде

- Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышлары үткәрелде:

- Полянка авылында 2024 елның 7 февралендә. 11:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Полянка авылы, 1 нче йорт - кибет бинасы янында;

- Шуран авылында 2024 елның 7 февралендә 11:30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Шуран авылы, Кооператив урамы, 32 нче йорт - мәктәп бинасы;

- Кече Елга авылында 2024 елның 7 февралендә, 12:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Кече Елга авылы, Совет урамы, 46 нчы йорт - Мәдәният йорты;

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2023 елның 29 ноябрендә Кече Елга авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 29 гыйнварыннан 2024елның 2 февраленә кадәр проект экспозициясен үткәрү барышында, шулай ук гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында кабул ителде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә Кече Елга авыл җирлегенең 2024елның14 февралендәге Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелгән.

Ачык тыңлауларда 21 кеше катнашты.

Ачык тыңлаулары нәтиҗәләре:

1.Халык тыңлауларын узган дип таныргa;

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын, 2024 елның 14 февралендәге

ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнар нигезендә әлеге нәтиҗәдән өземтәләр бирергә.

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре _________________________ Кондратьева А.А